**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.04.2023 Балык Бистәсе штп. № 109пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 27.10.2020 №218 карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминиятләштерү фонды турында» 14.07.2022 ел, №236-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 26.01.2023 ел, №1-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында карар бирәм:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 27.10.2020 №218 карары белән расланган торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. текст буенча «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 4 пунктның 5 абзацында, 3.5.1 пунктның 4 пунктчасында, 2.6 пунктның 4 пунктчасында «Россия Федерациясе Пенсия фонды» сүзләрен «Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фонды»сүзләре белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең веб-адрес буенча: http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталы» веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты житәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д.Н. Ризаевка йөкләргә.

Житәкче вазифаларын башкаручы А.А. Хәкимуллин